ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
июня 2018 года №2

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
Актаныш авыл җирлеге территориясендә сулыкларда
кешеләрнең үлемен кисәтү һәм булдырмау чаралары
турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003ел № 131-ФЗ Федераль законы, “Татарстан Республикасы территориясендә кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2006 ел № 306 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карары нигезендә, гражданнарның куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү һәм су объектларында бәхетсезлек очракларының санын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге учреждениеләре җитәкчеләренә авыл җирлеге территориясендә урнашкан сулыкларда бәхетсезлек очракларын кисәтү буенча профилактик эш алып барырга тәкъдим итәргә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге территориясендә халыкны коенуның рөхсәт ителмәгән урыннарында су коенуны тыю билгеләрен куярга.

3. Татарстан Республикасы территориясендә суда кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләре нигезендә җиһазландырылмаган һәм техник тикшерүдән үтмәгән су коену урыннарында су коену тыюларының үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтергә.

4.Җәйге каникул вакытында гомуми белем бирү учреждениеләренең мәктәп яны лагерьларында һәм «Бүләк» сәламәтләндерү лагеренда «су объектларында үз-үзеңне тоту һәм куркынычсызлык кагыйдәләре» темасына дәресләр оештырырга, авыл җирлеге территориясендә урнашкан сулыкларда балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрү мәсьәләсен карарга.

5.Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- «Татмедиа» АҖ су объектларында хәвефсез тәртип турында халык белән пропаганда эше алып барырга;
- Актаныш МР Актаныш авыл башкарма комитетының халык дружинасына «ФОРПОСТ» волонтерлары һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча участок хезмәткәрләре белән берлектә кешеләрнең күпләп сулыкларга чыгу урыннарын күзәтүне оештырырга.

6. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Шәрәпов